Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Полянка авыл җирлеге Советы

# КАРАР

№ 90 22.11.2024 ел

«Туристлык салымы турында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 33.1 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2025 елның 01 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Полянка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә туристлык салымын билгеләргә.

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә: 2025 елда – 1 процент, 2026 елда – 2 процент, 2027 елда – 3 процент, 2028 елда - 4 процент, 2029 елдан башлап-5 процент.

3. Салым түләү тәртибен Россия Федерациясе Салым кодексының 418.8 статьясы нигезендә билгеләргә.

4. Вакытлыча яшәү буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясе салым базасына кертелми торган физик затлар категорияләре Россия Федерациясе Салым кодексының 418.4 статьясының 2 пункты белән билгеләнгән.

5. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә туристлык салымын исәпләү тәртибе Россия Федерациясе Салым кодексының 418.7 статьясы нигезендә билгеләнә.

Россия Федерациясе Салым кодексының 418.7 статьясы нигезендә исәпләнгән туристлык салымы суммасы 100 сумның тапкырлавы һәм яшәү тәүлеге саны буларак исәпләнгән минималь туристлык салымы суммасыннан кимрәк булган очракта, туристлык салымы суммасы минималь туристлык салымы күләмендә билгеләнә.

6. Әлеге карарның 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керүен билгеләргә.

7. Әлеге карарны Полянка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга. http://spasskiy.tatarstan.ru/, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru//.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Полянка авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Полянка авыл җирлеге башлыгы: А.Ю.Царев

СОВЕТ ПОЛЯНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ПОЛЯНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА